# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2022 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге  131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 17 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; мобилизациялелэрнен  гаилә әгъзаларыннан тыш, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Карашай Саклау торак пунктында су җибәрү өчен янгын ранецлары, су өчен савытлар, трейлер һәм насос сатып алу;

2) Карашай Саклау торак пунктында МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) Карашай Саклау торак пунктында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны вакытлыча җыеп алу һәм чистарту (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне түләү) ;

4) призлар, азык-төлек җыелмалары алу; бәйрәмнәр үткәрү өчен туклануны оештыру (Авыл коне, инвалидлар көне, Өлкәннәр көне, юбилярлар, әфганчылар турнирын уздыру, авганец ветеранына мемориаль такта алу );

5) Карашай Саклау т. п. зираты өчен каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар, мотобур, Триммер сатып алу;

6) Карашай Саклау торак пунктында җиләк-җимеш агачлары үсентеләрен сатып алу һәм утырту, агач утырту өчен махсус техниканы арендалау (килешү буенча эшләр өчен түләү); Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 230 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -  135 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 135 _катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен  0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, мобилизациялелэрнен  гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Карашай Саклау торак пунктында су җибәрү өчен янгын ранецлары, су өчен савытлар, трейлер һәм насос сатып алу;

2) Карашай Саклау торак пунктында МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) Карашай Саклау торак пунктында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны вакытлыча җыеп алу һәм чистарту (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне түләү) ;

4) призлар, азык-төлек җыелмалары алу; бәйрәмнәр үткәрү өчен туклануны оештыру (Авыл коне, инвалидлар көне, Өлкәннәр көне, юбилярлар, әфганчылар турнирын уздыру, авганец ветеранына мемориаль такта алу );

5) Карашай Саклау т. п. зираты өчен каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар, мотобур, Триммер сатып алу;

6) Карашай Саклау торак пунктында җиләк-җимеш агачлары үсентеләрен сатып алу һәм утырту, агач утырту өчен махсус техниканы арендалау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева